ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**Приказ** **Боерык**

16.05.2018 г. Казань № 124-од

Татарстан республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты белән бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында

2011елның 20 гыйнварыннан 13 номерлы “Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару тәртибен, аучылык билетының формасын раслау турында”гы Россиянең Табигать министрлыгы боерыгын , 2010 елның 2 ноябреннән “Татарстан Республикасының башкарма хакимият әгъзаларының хезмәт күрсәтүләре буенча адмистратив регламентларны эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында ”гы 880 номерлы Татарстан Республикасы министрлар Кабинетының карарын тормышка ашыру һәм физик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү, Татарстан республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының структур бүлекчәләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшчәнлекне регламентлаштыру һәм стандартлаштыру максаты белән боерам:

1. Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсенең 12.05.2016 елдан 89-од номерлы “Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе белән бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында”гы боерыгын көчен югалткан дип танырга.
2. Кушылып бирелгән Татарстан республикасының Биологик ресурслар

буенча дәүләт комитеты белән бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентын расларга.

3. Татарстан республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты хезмәткәрләренә Регламентның кагыйдәләрен тотуны һәм аның белән каралган туры килүче документларны алып баруны тәэмин итәргә.

4. Хокукый эш буенча алдынгы киңәшче В.В. Фугинга бу боерыкны дәүләт теркәвенә һәм Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүматлар порталында рәсми бастыру өчен Татарстан Республикасының Юстиция Министрлыгына юнәлтергә.

5. Боерыкның үтәлүе артыннан тикшерүне рәис урынбасары Ю.Б.Матвеевка тапшырырга.

Рәис вазыйфаларын үтәүче Ю.Б.Матвеев

16.05.2018 елдан 124-од номерлы
Татарстан республикасының
Биологик ресурслар буенча дәүләт
комитеты Боерыгы белән расланды

Татарстан республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты белән бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламенты

## 1. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Татарстан республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты белән бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламенты ( алга таба – регламент) бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели ( алга таба – дәүләт хезмәте)

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар –бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын алу яки гамәлдән чыгару өчен Комитетка мөрәҗәгать иткән, гражданлык кануннары белән тәңгәл килеп, гражданлык эшчәнлегенә ия, алдан уйлап эшләнгән җинаять эше өчен хөкемгә тартылуы булмаган яки өстеннән алынган һәм аучылык таләпләре белән танышкан физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче булып Татарстан республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты килә ( алга таба – Комитет), Комитетның хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлекләре.

1.3.1. Комитетның урнашу урыны: Казан, Кәрим Тинчурин урамы, 29 йорт.

Комитетның эш вакыты: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00-18.00, җомга 9.00-16.45. Төшке аш 13.00-13.45.

Иҗтимагый транспорт белән “Тинчурин” тукталышына кадәр :
автобуслар № 1, 6, 8, 31, 53, 54, 85, 99, 99 а;
троллейбуслар № 20, 21;
трамвай № 7;
«Ахтямов» тукталышына кадәр:
автобуслар № 5, 23, 56, 68, 72,79.

Бинага керү үткәрү кәгазе яки шәхесне раслый торган документ буенча.

Комитетның хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлекләренең урнашу урыны, мәгълүмат өчен телефоннары, электрон адресы турында мәгълүмат регламентның белешмәләр кушымтасында бирелгән.

Комитетның район ( районара) бүлекләренең эш тәртибе:
дүшәмбе, пәнҗешәмбе, җомга,шимбә, якшәмбе 9.00-18.00.
Ял көннәре сишәмбе,чәршәмбе

Төшке аш 13.00-13.45.

Комитетның белешмәләр өчен телефоны: (843) 211-66-94.

Мәгълүмати-телекомммуникатив “Интернет” челтәрендә Комитетның рәсми сайт адресы http://www.ojm.tatar.ru, электрон почта адресы ojm@tatar.ru.

Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Комитетта, Комитетның хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлекләрендә, гариза бирүчеләр белән эшли торган бүлмәсендә урнаштырылган, дәүләт хезмәте турында турыдан-туры күреп һәм текстлы мәгълүмат булган, дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар ярдәмендә;

2) “Интернет” челтәре аша:

Комитетның рәсми сайтында (http://www.ojm.tatar.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында(http://www.gosuslugi.tatar.ru/);

3) Комитетка, Комитетның хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлекләренә телдән мөрәҗәгать итеп ( телефон аша яки шәхси);

4) Комитетка, Комитетның хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлекләренә язмача мөрәҗәгать итеп (шул санда Комитетның рәсми сайты ярдәмендә җибәрелгән электрон документ аша)

Мәгълүмати стендларда урнаштырылган мәгълүмат, бу Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында бирелгән дәүләт хезмәте турындагы мәгълүматны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге актлар белән җайга салына: 27.06.2006 ел 152-ФЗ номерлы “Шәхси мәгълүматлар турында”гы Федераль канун белән (Россия Федерациясенең кануннар җыентыгы, 2006, № 31 (1б), 3451 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

24.07.2009 ел 209-ФЗ номерлы “Ау турында һәм аучылык байлыкларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль канун белән; (Россия Федерациясенең кануннар җыентыгы, 27.07.2009, № 30, 3735 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып) (алга таба – 209-ФЗ номерлы Федераль канун);

27.07.2010 ел. № 210-ФЗ номерлы “ Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль канун белән (Россия Федерациясенең кануннар җыентыгы, 2010, № 31 (1б), 3451 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

07.05.2012 ел. 601 номерлы “Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында”гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы (алга таба – 601 номерлы РФ Президенты Боерыгы) (Россия Федерациясенең кануннар җыентыгы, 2012, № 19, 2338маддә);

06.09.2010 ел. 345 номерлы “Дәүләт аучылык хуҗалыгы реестрының катнашмасы һәм алып бару тәртибе, анда булган документлаштырылган мәгълъматны җыю һәм саклау һәм кызыксынган затларга тапшыру турында Кагыйдәнамәне раслау турында” Россиянең Табигать министрлыгы боерыгы белән (башкарма хакимиятнең федераль әгъзасының норматив актлар бюллетене, 2011,№4, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып) ( алга таба - Россия Табигать министрлыгының 345 нче номерлы боерыгы);

20.01.2011 ел. 13 номерлы “Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару тәртибен, аучылык билетының формасын раслау турында”гы Россиянең Табигать министрлыгы боерыгы белән (Россия газеты.2011, № 66, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып) (алга таба - Россия Табигать министрлыгының 13 нче номерлы боерыгы яки Тәртип);

02.11.2010 ел. “Татарстан Республикасының башкарма хакимият әгъзаларының хезмәт күрсәтүләре буенча адмистратив регламентларны эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгешләр кертү турында”гы 880 номерлы Татарстан Республикасы министрлар Кабинетының карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр һәм республика башкарма хакимият әгъзаларының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 маддәсе)

15.12.2017елдан 996 номерлы “Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турында Кагыйдәнамәне раслау турында”гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары ( алга таба – Комитет турында Кагыйдәнамә) (Татарстан Республикасының кануннар җыентыгы, 2017, № 95, 3544 маддә).

1.5. Бу регламентта киләсе атамалар һәм билгеләмәләр кулланыла:

**бердәм федераль үрнәктәге аучылык билеты** – гамәл вакыты һәм урыны чикләнми торган, учет номеры һәм сериясенә ия булган документ. Документның формасы Россия Табигать министрлыгының 13 нче номерлы боерыгы белән расланган;

**дәүләт аучылык хуҗалыгы реестры** (алга таба - Реестр) – аучылык байлыклары турында, аларны куллану һәм саклау турында, аучылык биләмәләре турында, аучылар турында, аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек алып бара торган юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр турында документлаштырылган мәгълүматның системалы җыелмасын тәшкил итә.

**техник хата** – алар нигезендә мәгълүмат кертелгән документлардагы мәгълүмат белән,кертелгән документтагы(дәүләт хезмәте нәтиҗәсе) мәгълүматның туры килмәвенә китергән, дәүләт хезмәте күрсәтүче әгъза белән җибәрелгән, хата (хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата).

**дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ераклашкан эш урыны** – муниципаль районнарның авылларында гаризачыларга мәгълүмат бирү, документларны кабул итү һәм бирү тәрәзәсе.

Идарәара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба– ИЭХС) –электрон хәбәрләр чираты технологиясе аша, әгъзалар һәм оешмаларның үзара мәгълүмати системаларының бердәм документлаштырылган хезмәттәшлек итү ысулын тәэмин итә торган программалар һәм техник чаралар, программаларның асинхрон режимында үзара хезмәттәшлекне тәэмин итә торган, алар арасында турыдан-туры элемтә урнаштырырга таләп итми торган һәм тапшырыла торган электрон хәбәрләрне алу гарантиясе бирелгән, һәм электрон хәбәрләр үзара хезмәттәшлек итү системасында мәгълүматлар хәрәкәте тарихы турында мәгълүматлар, ә шулай ук үзара хезмәттәшлекне тәэмин итүче программалар һәм техник чаралар, үзара хезмәттәшлек итү системасы аша аларның мәгълүмати системаларына керү мөмкинлеген тәэмин итәрлек, әгъзалар һәм оешмалар куллана торган программалар һәм техник чаралар турында мәгълүматларны кертkән, мәгълүмат базасын үз эченә ала торган федераль дәүләт мәгълүмати система

Бу регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – гариза) турында гариза астында, дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать тора (27.07.2010 № 210-ФЗ Федераль канунның 2 м.1 п.). Гариза, бу регламентның 1нче кушымтасында китерелгән форма буенча тутырыла.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына куела торган таләпнең исеме | Стандартка куела торган таләпнең эчтәлеге | Таләпне яки дәүләт хезмәтен билгели торган норматив акт |
| --- | --- | --- |
| 2.1.Дәүләт хезмәтенең атамасы | Татарстан республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты белән бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару (алга таба- аучылык билеты). | №209-ФЗ Федераль канунның 21 м.,2 п. |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче әгъзаның атамасы | Татарстан республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты, Комитетның хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлекләре | Комитет турында Кагыйдәнамәнең 4.1.43 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | гариза буенча аучылык билетын бирү ( бирмәү), гамәлдән чыгару | Тәртипнең 17 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул санда дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган, оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген, РФ кануннары белән каралган мөмкинлек булган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакытын истә тотып | Аучылык билеты,гаризаны теркәгәннән соң, биш эш көне эчендә бирелә;<br>Аучылык билеты,алда алган аучылык билетын гамәлдән чыгару турындагы гаризаны теркәгәннән соң, биш эш көне эчендә гамәлдән чыгарыла;<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүвакытын туктатып тору каралмаган. | Тәртипнең 10 п.<br><br>Тәртипнең 19.1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен канун яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге,гариза бирүче белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә, аларны күрсәтү тәртибе. | Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын алу турында гариза (1 нче кушымта);<br>Аклы-каралы яки төсле, 30-40 мм зурлыктагы, йөз туры караган, ачык, баш киемсез төшкән ике шәхси фотография;<br>Шәхесне белдерә торган төп документның күчермәсе (гаризаны электрон рәвештә бирү очрагында – скан-күчермә)<br>Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын гамәлдән чыгару турында гариза ( 2 нче кушымта);<br>Дәүләт хезмәтен алыр өчен гариза бланкын гариза бирүче Комитетка шәхси килеп алырга мөмкин.<br>Бланкның электрон формасы Комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа кушылган документлар, гариза бирүче белән, кәгазьдә киләсе ысуллар белән тапшырыла алалар:<br>шәхси (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат белән);<br>почта аша.<br>Документлар, гариза бирүче белән, шулай ук электрон документ рәвешендә , “Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы” федераль мәгълүмат системасы яки җирле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталлары аша тапшырылырга мөмкин. Аңа шәхси фото беркетелә. Фотога куелган таләпләр: | Тәртипнең 8нче п.<br><br><br><br><br><br><br><br><br>Тәртипнең 17 нче п. |

| | | |
|---|---|---|
| | кушылып бирелгән файлдагы рәсемнең форматы - JPEG яки JPEG 2000;<br>беркетелгән фотографиянең минимум рөхсәте 450 dpi ким булмаска тиеш;<br>фотография 24-битлы төсле киңлектә яки 8-битлы аклы-каралы киңлектә үтәлергә мөмкин;<br>беркетелгән фотографиянең максимум зурлыгы 300 кб артмаска тиеш; | |
| 2.6. Дәүләт әгъзалары, җирле үзидарә әгъзалары һәм башка оешмалар карамагындагы, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган кирәкле документларның тулы исемлеге, ә шулай ук гаризачылар белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә; | Гариза бирүченең алдан уйлап эшләнгән җинаять эше өчен хөкемгә тарттырылган булуы (булмавы) яки өстеннән алынган булуы турында мәгълүмат – Татарстан Республикасы буенча Россиянең ЭЭМда.<br>Гариза бирүченең паспорты чын булуын раслау турында мәгълүмат (дәүләт хезмәте электрон рәвештә күрсәтелгән очракта)- Татарстан Республикасы буенча ЭЭМның күченү сораулары буенча Идарәсендә.<br>Документларны бирү ысуллары һәм алу тәртибе, бу Регламентның 2.5. пунктында билгеләнгән.<br>Дәүләт әгъзалары, җирле үзидарә әгъзалары һәм башка оешмалар куллануында булган, өстә күрсәтелгән документларны, гариза бирүчедән таләп итәргә тыела. | Тәртипнең 1нче пункты |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен | Килештерү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүче башкарма әгъза тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте әгъзалары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Бу регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документны бирмәү. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>- Гариза бирүче белән бирелгән документларда дөрес мәгълүмат күрсәтмәү.<br>- Гариза бирүченең алдан уйлап эшләнгән җинаять эше өчен хөкемгә тарттырылуы булуы яки өстеннән алынмаган булуы. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, түләүнең күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп, | Мәҗбүри һәм зарури хезмәтләр таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре. | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәтен алу турында мөрәҗәгать биргәндә яки андый хезмәтнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтү вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш. | РФ Президентының 601нче номерлы боерыгы |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты, шул санда электрон рәвештә | Гариза кергән көнне.<br>Электрон рәвештә, ял (бәйрәм) көнендә кергән мөрәҗәгать, ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр, шул санда күрсәтелгән объектлар, Россия Федерациясенең инвалидларны иҗтимагый яктан яклау турындагы кануны белән тәңгәл килеп, инвалидлар йөрерлек өчен җайлы булырга тиеш, шулай ук андый хезмәтне күрсәтү турында турыдан-туры күренә торган, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат белән җиһазландырылырга тиеш. | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы һәм янгын сүндерү системасы белән,мәгълүмат стендлары белән,документларны тутыру өчен яраклы булган җиһазлар булган биналарда алып барыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү урынына инвалидлар өчен җайлы керү-чыгу урыннары тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында турыдан-туры күренә торган, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып җиһазландырылырга тиеш. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән файдалана алу мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре, шул санда дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүченең урындагы затлар белән аралашу саны һәм вакыты, дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган, күпфункцияле үзәкләрдә алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган, күпфункцияле үзәкләрнең ераклашкан эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен алу барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге (шул санда мәгълүмати-коммуникация технологияләрен кулланып) | Дәүләт хезмәтеннән файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>Комитет биналарының җәмәгать траспортына якын булу;<br>гаризалар кабул итәр өчен саны буенча җитәрлек белгечләр булу, шулай ук документлар кабул итәр өчен бина булу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүматның “Интернет” челтәре мәгълүмат ресурсларында, мәгълүмат стендларында, Комитетның рәсми сайтында булу;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>Комитет белгечләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү барышында бу регламентны бозу турында нигезле шикаятьләр булмау;<br>гариза бирүченең Комитет белгечләре белән аралашу саны;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны шәхси тапшырганда - ике тапкырдан да артмаска тиеш (консультацияләрне санамыйча) ;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша яки электрон рәвештә | |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшырганда – бердән дә артмаска тиеш.<br>Гариза бирүченең Комитет хезмәткәре белән кабул ителү вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мәгълүмат гариза бирүче белән http://ojm.tatarstan.ru сайтта, Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/),Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), федераль дәүләт мәгълүмат системасы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы” (http://www.gosuslugi.ru/) алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәкләрнең ераклашкан эш урыннарында алу мөмкинлеге юк. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте электрон рәвештә информация-технология һәм коммуникация инфраструктурасын кулланып бирелә, шул санда федераль дәүләт мәгълүмат системасы “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы” һәм региональ Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы. | 210-ФЗ номерлы Федераль канун |

**3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул санда административ процедураларны электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре, ә шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торганкүпфункцияле үзәкләрнең ераклашкан эш урыннарында башкару үзенчәлекләре**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндәге гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы

3.1.1.Дәүләт хезмәтен күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

гариза бирүчеләрне консультацияләү, шул санда гаризаны теркәүдә булышу;

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы әгъзаларга идарәара мөрәҗәгатьне әзерләү һәм җибәрү;

аучылык билетын бирү (бирүдән баш тарту) яки гамәлдән чыгару турында карарны әзерләү;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен тапшыру;

техник хатаны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы әлеге административ регламентның 5нче һәм 6 нчы кушымталарында тәкъдим ителә.

3.2. Гариза бирүчене консультацияләү, шул санда гаризаны рәсмиләштерүдә булышу.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алырга дип,шул санда гаризаны рәсмиләштерү өчен, Комитетка яки Комитетның хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлегенә телефоннан һәм (яки) электрон почта аша(e-mail: ojm@tatar.ru), Татарстан Республикасының рәсми порталындагы интернет-кабул итү бүлмәсе аша (http://ojm.tatarstan.ru.) мөрәҗәгать итә.

Комитетның яки Комитетның хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлегенең дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы белгече (алга таба – Комитет белгече) , вазыйфаи регламент белән тәңгәл килеп, гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән, гаризаны рәсмиләштерергә булыша.

Процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

3.3. Аучылык билетын алу турында гаризаны һәм документларны кабул итү һәм рәсмиләштерү.

3.3.1. Гариза бирүче, Комитетка яки Комитетның хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлегенә , Регламентның 2.5 пунктына туры китереп, җибәрелгән документларның исемлеге белән, шәхси яки почта аша яки электрон документ рәвешендә , “Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

порталы” федераль мәгълүмат системасы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күп функцияле үзәге аша аучылык билетын алу турында гаризаны һәм документларны юнәлтә.

Аучылык билетын алу турында гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.2. Комитет белгече түбәндәгеләрне эшли:

бөтен кирәкле документлар булуын тикшерә

әлеге Административ регламентның 2.8. бүлеге белән каралган, документларны кире кайтару өчен нигез булган очракта, Комитет белгече, гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен киртә булганы турында хәбәр итә һәм кире кагуны нигезләп, телдән яки гаризада күрсәтелгән почта адресы яки электрон почта аша, документларны кире бирә.

документларны кире кайтару өчен нигез булмаса, Комитет белгече гаризаны һәм барлык документларны кабул итә һәм теркәү журналына теркәп куя.

Шәхси мөрәҗәгать иткән очракта, Комитет белгече, гариза бирүчегә гаризаның документларны кабул итү вакытын, теркәү номерын күрсәтеп, гаризаның күчермәсен тапшыра;

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар гариза биргән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы, документларны кабул итү вакытын, номерын, дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын күрсәтеп, гаризаның күчермәсен гариза бирүчегә тапшыру яки кире кагу сәбәпләрен нигезләп, гариза бирүчегә кайтарылган документлар.

3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы әгъзаларга, идарәара мөрәҗәгатьне формалаштыру һәм җибәрү.

Комитет белгече: Россия Федерациясенең Эчке эшләр министрлыгының 07.11.2011елдан 1121 номерлы “Россия Федерациясенең Эчке эшләр министрлыгының хөкемгә тартылу яки җинаять эзәрлекләве очрагы турында яки җинаять эзәрлекләве туктатылутурында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү турында Административ регламентны раслау турындагы” боерыгы белән тәңгәл килеп, идарәара мәгълүмати аралашу тәртибендә эчке эшләр әгъзасына гариза бирүченең, уйлап эшләнгән җинаять эше өчен, хөкемгә тартылганы ( тартылмаганы) турында мәгълүмат бирүне формалаштыра һәм җибәрә;

идарәара мәгълүмати аралашу тәртибендә Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ күченеш сораулары буенча Идарәсенә, гариза бирүченең паспорты гамәлдә булуын раслау турында мәгълүмат бирүне формалаштыра һәм җибәрә.

Бу пунктта күрсәтелгән процедура, гариза теркәлгәннән соң, бер эш көнендә башкарыла.

Мәгълүматлар ИЭХС ярдәмендә тапшырылалар.

Процедура нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ күченеш сораулары буенча Идарәгә һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы идарәсенә җибәрелгән мөрәҗәгать.

3.5. Аучылык билетын бирү ( бирүдән баш тарту) турында карарны әзерләү.

3.5.1. Башлык, Дәүләт комитетының хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге

буенча район (районара) бүлегенә өлкән белгече ( алга таба – Комитетның район белгече), ә шулай ук Комитетның административ һәм суд практикасы бүлегенең өлкән белгече (алга таба – Бүлек белгече) , эчке эшләр әгъзасының уйлап эшләнгән җинаять эше өчен, хөкемгә тартылганы (тартылмаганы) турында мәгълүмат бирүне соравына җавап нигезендә, бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итә.

Регламентның бу пункты белән билгеләнгән процедура, сорауларга җавап алган көннән соң, бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкарылырга җибәрелгән документлар.

3.5.2. Бу регламентның 2.9. пункты белән каралган нигезләр булган очракта, Бүлек белгече:

дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат документлар белән бергә Комитетның административ һәм суд практикасы бүлеге башлыгына (алга таба – Бүлек башлыгы) раштыруга җибәрелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар белән бергә Бүлек башлыгына яраштыруга җибәрелгән дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты.

3.5.3. Бүлек башлыгы дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын яраштыра һәм имза куя.

Процедура нәтиҗәсе: имза куелган дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат.

Процедуралар нәтиҗәсе: барлык документлар белән бергә Комитетның кабул итү бүлмәсенә җибәрелгән, имза куелган дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.5.4. Комитетның кабул итү бүлмәсе белгече хатны терки һәм гариза бирүчегә почта аша яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша җибәрә. Бирелгән документларның күчермәләре Комитетның кабул итү бүлмәсендә саклanyрга кала.

3.5.5. Бу регламентның 2.9. пункты белән каралган нигезләр булган очракта, Комитетның район белгече:

дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат әзерли;

дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хатка имза куя;

хатны терки һәм гариза бирүчегә почта аша җибәрә. Документларның бирелгән күчермәләре ук Комитетның административ һәм суд практикасы бүлегенә саклануга биреләләр.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында имза куелган хат.

Процедура нәтиҗәсе: Комитетның административ һәм суд практикасы бүлегенә юнәлтелгән документлар белән, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында имза куелган хат.

Бу регламентның 3.5.2. – 3.5.5. пунктлары белән урнаштырылган процедуралар бер эш көнендә башкарылалар.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә почта аша яки бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында теркәлгән хат.

3.6. Гариза бирүчегә аучылык билетын бирү.

3.6.1. Бүлек Белгече, Комитетның район хезмәткәре, документлар һәм мәгълүматлар бу регламентның 2.9. пункт таләпләренә туры килгән очракта:

бу регламентның 3.6.2. пункты белән каралган процедураларны башкара.

3.6.2. Бүлек белгече:

аучылык билетының бланкасын тутыра, гариза бирүченең фотографиясен ябыштыра һәм Комитет рәисенә яки аның урынбасарына, алар булмаган очракта - хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге Идарәсе башлыгына имза куйдыртырга юнәлтә;

мәгълүматларны дәүләт аучылык хуҗалыгы реестрына кертә ( алга таба – Реестр);

мәгълүматларны Реестрга кертү турында белдерү кәгазе проектын әзерли ( алга таба – Белдерү кәгазе) ( 3нче кушымта) һәм имза куйдыртырга Бүлек башлыгына юнәлтә.

Процедура нәтиҗәсе: аучылык билетының тутырылган бланкасы һәм Реестрга кертелгән мәгълүматлар, әзерләнгән һәм имза куйдыртырга Бүлек башлыгына юнәлтелгән Белдерү кәгазе.

Комитетның район хезмәткәре:

аучылык билетының бланкасын тутыра, гариза бирүченең фотографиясен ябыштыра һәм аучылык билетына имза куя;

мәгълүматларны Реестрга кертә;

Белдерү кәгазе проектын әзерли һәм аңа имза куя;

Белдерү кәгазен терки һәм аны гариза бирүчегә почта аша заказлы хат белән җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: аучылык билетының тутырылган бланкасы, Реестрга кертелгән мәгълүматлар, имзаланган һәм гариза бирүчегә почта аша юнәлтелгән Белдерү кәгазе.

3.6.3. Бүлек башлыгы белдерү кәгазе проектына имза куя.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы белән имза куелган Белдерү кәгазе.

Бу Регламентның 3.6.1.-3.6.3. пунктлары белән урнаштырылган процедуралар, регламент белән каралган алдагы процедура тәмамланганнан соң, бер эш көнендә башкарылалар.

Процедуралар нәтиҗәсе: имза куелган һәм кабул итү бүлмәсенә юнәлтелгән белдерү кәгазе.

3.6.4. Комитетның кабул итү бүлмәсе хезмәткәре Белдерү кәгазен терки һәм заказлы хат белән почта аша гариза бирүчегә юнәлтә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә почта аша җибәрелгән, рәсмиләштерелгән Белдерү кәгазе.

3.6.5. Комитет рәисе яки Дәүләт комитетының хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлек башлыгы аучылык билетының

бланкасына имза куя, мөһер суга һәм бланкны, гариза бирүче белән алу өчен, Бүлек белгеченә тапшыра.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүче белән алу өчен, Бүлек белгеченә тапшырылган, имза куелган аучылык билеты.

3.6.6. Бүлек белгече гариза бирүчегә аучылык билетын шәхси тапшыра яки гариза бирүченең адресы буенча җибәрү өчен, аны кабул итү бүлмәсе белгеченә юнәлтә.

3.6.4.-3.6.6. пунктлары белән урнаштырылган процедуралар, аучылык билетына имза куйганан соң, бер эш көнендә башкарылалар.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән яки почта аша юнәлтелгән аучылык билеты.

3.6.7. Аучылык билетын югалткан очракта, Комитетка яки Дәүләт комитетының хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлегенә, бу регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар кергәннән соң, 5 эш көне эчендә, яңа аучылык билеты бирелә. Гаризада аучылык билетын югалту турында язылa.

3.7. Аучылык билетын гамәлдән чыгару.

3.7.1. Гариза бирүче Комитетка яки Дәүләт комитетының хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлегенә аучылык билетын гамәлдән чыгару турында гариза белән шәхси мөрәҗәгать итә. ( 2нче кушымта)

3.7.2. Бүлек белгече, Комитетның район хезмәткәре:

гаризаны кабул итә һәм терки;

гариза бирүчегә документларны кабул итү вакытын, теркәү номерыын, дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын язып, гаризаның күчермәсен тапшыра.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм рәсмиләштерелгән гариза.

3.7.3. Бүлек белгече:

аучылык билетын гамәлдән чыгару турында мәгълүматны Реестрга кертә;

мәгълүматларны Реестрга кертү турында белдерү кәгазе проектын әзерли (алга таба – Белдерү кәгазе) (4нче кушымта) һәм имза куйдыртырга Бүлек башлыгына юнәлтә.

Процедура нәтиҗәсе: Реестрга кертелгән мәгълүматлар, әзерләнгән һәм имза куйдыртырга Бүлек башлыгына юнәлтелгән Белдерү кәгазе.

3.7.4. Комитетның район хезмәткәре:

аучылык билетын гамәлдән чыгару турында мәгълүматларны Реестрга кертә;

мәгълүматларны Реестрга кертү турында Белдерү кәгазе проектын әзерли (алга таба – Белдерү кәгазе) (4нче кушымта) һәм аңа имза куя.

Процедура нәтиҗәсе: Реестрга кертелгән мәгълүматлар, имза куелган Белдерү кәгазе проекты.

3.7.5. Бүлек башлыгы  Белдерү кәгазе проектына имза куяю  Имза куелган белдерү кәгазен Бүлек башлыгы  Комитетның кабул итү бүлмәсенә юнәлтә.

Процедура нәтиҗәсе: имза куелган һәм Комитетның кабул итү бүлмәсенә юнәлтелгән Белдерү кәгазе.

3.7.6. Комитетның кабул итү бүлмәсе белгече Белдерү кәгазен терки һәм аны гариза бирүчегә почта аша заказлы хат белән юнәлтә.

Бу регламентның 3.7. пункты белән урнаштырыла торган процедуралар, гариза алган көннән алып, биш эш көнендә башкарылалар.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә почта аша җибәрелгән, теркәлгән Белдерү кәгазе.

3.7.7. Кайтарылган аучылык билетында, аның гамәлдән чыгарылуы турында языла.

3.8. Техник хатаны төзәтү:

Аучылык билетын яңадан чыгару, элек бирелгән аучылык билетында җибәрелгән, техник хатаны төзәтү белән бәйле рәвештә үтәлә.

Гариза бирүчегә бирелгән хаталы аучылык билетын теркәп, аучылык билетын яңадан чыгару, техник хатаны төзәтү турында теркәлгән гариза (тәкъдим ителгән форма бу регламентның 7нче кушымтасында бирелгән) нигезендә үтәлә.

3.8.1.Бүлек белгече:

- гаризаны кабул итә һәм терки;

- документларны алу вакыты һәм теркәлү номеры билгеләнгән гариза күчермәсе, гариза бирүчегә шәхси яки почта аша яки электрон почта аша ( аның теләге буенча) тапшыра.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедуралар, гариза теркәлгәннән соң бер эш көне эчендә башкарылалар.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.8.2. Бүлек белгече:

аучылык билетын яңадан ясый;

аучылык билетын яңадан чыгару турында хат проектын әзерли һәм яраштыру өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Бу пункт белән каралган процедуралар, гаризаны Бүлек белгеченә биргән көннән алып, бер эш көне эчендә башкарылалар.

Процедуралар нәтиҗәсе: яраштыру өчен Бүлек башлыгына җибәрелгән өземтә.

3.8.3. Бүлек башлыгы әзерләнгән аучылык билетының дөреслеген тикшерә, хат проектын яраклаштыра һәм аларны Комитет рәисенә имза куярга җибәрә.

Бу пункт белән билгеләнгән процедура, Бүлек башлыгына, яраштыру өчен, Рөхсәтнамә һәм хат проекты кергән көнне эшләнә.

Процедура нәтиҗәсе: Комитет рәисенә имза куярга җибәрелгән аучылык билеты һәм хат проекты.

3.8.4. Комитет рәисе хат проектына һәм аучылык билетына имза куя һәм Бүлеккә җибәрә.

Бу пункт белән билгеләнгән процедура, Бүлек башлыгыннан хат проекты кергән көнне эшләнә.

Процедура нәтиҗәсе: яраштырылган хат проекты, аучылык билеты.

3.8.5. Бүлек белгече Комитет рәисе белән кул куелган дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы хатны терки. Ул хат аучылык билеты белән бергә гариза

бирүчегә яки аның вәкаләтле затына (ышаныч кәгазе булган очракта) имза астына бирелә.

Бу пункт белән билгеләнгән процедура, гариза бирүче яки аның вәкаләтле заты килгән көннән алып, бер көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган хат һәм техник хатасы төзәтелгән аучылык билеты.

3.9. Күп функцияле үзәк аша, КФҮ ераклашкан эш урыны аша дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күп функцияле үзәк аша, күп функцияле үзәкнең ераклашкан эш урыны аша дәүләт хезмәте күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшерү формалары һәм тәртибе

4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең, административ процедуралар белән билгеләнгән, эш тәртибен саклау артыннан агымдагы тикшерү, бу регламентның кагыйдәләрен тотуны һәм саклауны тикшерү юлы белән, Комитет рәисе белән үткәрелә.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү артыннан тикшерү Комитетның вазыйфаи затлары белән үтәлә. Тикшерүче вазыйфаи затларның вәкаләтләре, Комитетның бүлекләр турында кагыйдәнамәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү, тикшерүләр уздыруны, урындагы затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьле гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләрен карау, алар буенча карар кабул итүне һәм җавап әзерләүне үз эченә ала.

